Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Нижнебишевского
сельского поселения Заинского
муниципального района

Ул. Центральная, д. 46, с. Нижнее
Бишево, Заинский район, 423514

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
башкарма комитеты

Үзәк урам, 46 нчы йорт,
Түбән Биш авылы, Зәй районы,
423514

Телефон, факс 68-4-47. Электронный адрес: Nbsh.Zai@tatar.ru, сайт:
www.nigneebishevo.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

24.12.2018 ел — № 20

**Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставы, «Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 05 февралендәге 118 номерлы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар итте:**

1. Түбән Биш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Д.В.Насертдинов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 24 декабрендәге
20 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Түбән Биш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары киләсе календар елның 15 февраленә кадәр Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, җирле референдумда (җыенда) катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан түләнә.

3. Түләми тору өчен нигезле сәбәпләр булып түбәндәгеләр торырга мөмкин:

а) вакытлыча хезмәткә яраксызлык (6 айдан артык),

б) оешманы бетерү, оешма хезмәткәрләренең санын яки штатын кыскарту сәбәпле эштән азат ителү,

гражданнарга гариза нигезендә түләүне кичектерү ике айдан да артык булмаган вакытка бирелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерү) бланкы турында гражданнарга хәбәр җирлекнең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру, кул куйдырып, кулга бирү юлы белән җиткерелә, почта элемтәсе аша җибәрелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү юлы белән (исәп-хисап оешмалары), Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы аша башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган документлар булып приход касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 24 декабрендәге
20 номерлы карарына
2 нче кушымта

______________________ авыл җирлеге бюджетына бер тапкыр түләнә торган салымны түләү турында _____ номерлы
ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮ)

Түләүченең
Ф.И.А.__________________________________________________________________
Адресы: ________________________________________________________________
Сезгә _______________________________________нигезендә ____________________
кадәр _________________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр _________________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча салым түләргә кирәк.

Банк БИК _______________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № _________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________

Түләүнең
билгеләнеше__________________________________________________________

Җитәкче __________________ _________________________________________
М.У. (имза) (имза тулысынча)

\- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерү) No ____

____________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
бюджетына үзара салым буенча _________________ суммада бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.А. _____________________________________
Адресы: ______________________________________________________________
Алынган «__» ________________ 20__ ел___________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Өзеп бирелә торган квитанция тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылганда төпсә____________авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*